*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 57**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Төркем булып йөзгән авыр болытлар бертуктаусыз куера бара.(А.Расих)*
1) төркем
2) йөзгән
3) бертуктаусыз
4) куера

2. Борын тартыклары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) [г], [к], [ж]
2) [м], [н], [ң]
3) [һ], [л], [з]
4) [с], [ф], [ш]

3. Калын сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Изгелек эшен озакка сузарга ярамый.
2) Инсафлының теле саф.
3) Тел күңелнең көзгесе.
4) Акылың булса, ачу саклама.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) әмма
2) өстәлдәге
3) апаларыбызга
4) барганнар

5. Хаталы язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) маэмай
2) кәгазь
3) янгыр
4) палас

6. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең синонимын билгеләгез. **(2 балл)**
*Нәҗип **сандугачының** балалар чыгарганын күрми калды.*
1) кошчык

2) былбыл
3) карлыгач
4) һөдһөд

7. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Бүтән өмәләрдән аермалы буларак, каз өмәсе* - .....
1) казлар бәйрәме.
2) язын үткәрелә.
3) башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе.
4) тиз тәмамлана.

8. Тезмә сүз күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алъяпкыч
2) алтмыш
3) бака яфрагы
4) бер-ике

9. *Көчлерәк* сыйфатының дәрәҗәсен билгеләгез. **(2 балл)**
1) гади
2) кимлек
3) артыклык
4) чагыштыру

10. Эндәш сүз кулланылган җөмләне билгеләгез (тыныш билгеләре куелмаган). **(2 балл)**
1) Алсу Айдаровна балаларга татар телен укыта.
2) Алия белән Гөлназ бүген чана шуалар.
3) Гөлфия Мансуровна керергә ярыймы?
4) Балаларга өй эшен аңлаталар.

**II. Теоретик бирем.**

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән исемнәрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Исемнең килеш белән төрләнеше турында белгәннәрегезне языгыз. **(10 балл)**

Мин **бәхет_____** кайдан алырмын**,**
Туган **йорт_______** китсәм **гомер_____**?
Таш булып мин җансыз калырмын,
Сүз югалыр минем **телем________**.
Бер көн артык миңа мең **елд______**,
Айда түгел, туган илемдә! (*Н. Дәүли*)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз ясалыш чылбырында төшеп калган сүзне языгыз. **(5 балл)**

Яшел – ________________, яшелчәче

Өмет – _________________, өметсезлек

Аш –____________________, ашлама

Сабыр – ________________, сабырсызлык

Бүл –___________________, бүлмәдәш

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүз һәм аның килеп чыгышы ягыннан төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) дизель | 1) рус алынмасы |
| Ә) салам | 2) төрки-татар сүзе |
| Б) абый | 3) фарсы алынмасы |
| В) мәдрәсә | 4) гарәп алынмасы |
| Г) җиһан | 5) Европа алынмасы |

**Җавап :** ______________________

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, т...зелешеп,—
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми ....ич тә.
Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,

Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең оз....нлыгын сизмисез дә
Ә...кәгезнең сөйләгәне әкият берлә. (*Г. Тукай*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(3 балл)**

______________________________________________

4. *Берлә* сүзенең хәзерге татар телендәге сүзен языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________

5. “Кышкы кич” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________